**Республика Татарстан**
**Совет Кавзияковского**
**сельского поселения**
**Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районы Кэужияк авыл**
**җирлеге советы**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2019 ел 22 ноябрь Кәүҗияк авылы № 26

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге составына керүче Түбән Бикмәт авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге советы карар итте:

1. 2020 елда Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга:
- Бикмәт авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Бикмәт авылы территориясендә үлән чабу;
- каты көнкүреш калдыкларын күмү;
- зират өчен инвентарь сатып алу;
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Кәүҗияк авылы, Советская урамы, 66В йорт ; Түбән Бикмәт авылы адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны, Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы рәисе: Ф.А.Хөснетдинов